ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы икътисадын цифрлы нигездә трансформацияләүгә ярдәм итүче кече технологик компанияләр өчен салым ташламаларының нәтиҗәлелеге турында

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары Б.Ф. Габдрахмановның Татарстан Республикасы икътисадын цифрлы нигездә трансформацияләүгә ярдәм итүче кече технологик компанияләр өчен салым ташламаларының нәтиҗәлелеге турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы икътисадын цифрлы нигездә трансформацияләүгә ярдәм итүче кече технологик компанияләр өчен салым ташламаларының нәтиҗәлелеге турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кече технологик компанияләр өчен гамәлдәге салым ташламаларының нәтиҗәлелеген аларның Татарстан Республикасы икътисады үсешенә йогынтысы өлешендә мониторинглауны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә технологик компанияләр үсешенә мәгълүмати ярдәм итү буенча салым ташламалары бирүне үз эченә алган чаралар комплексын эшләргә, шулай ук, эксперт бергәлеген җәлеп итеп, салым ташламаларының Татарстан Республикасы икътисады үсешенә йогынтысын бәяләү күрсәткечләрен эшләргә.

3.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә кадрлар кытлыгы арткан шартларда белгечләр әзерләүне, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары базасында һөнәргә алдан әзерләүне, көчәйтергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына республика башкарма хакимиятенең тармак органнары белән берлектә кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәме күрсәтүнең хокук куллану тәҗрибәсенә еллык мониторинг оештырырга һәм кирәк булганда  Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 8 апреле
№ 163-VII ДСП